**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**2018 ел, 14 сентябрь** **№ 92**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында"гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы "Җирле референдум турында"гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 15 маддәсе, 2018 елның 13 сентябрендәге "Җирле референдум үткәрү инициативасы турында"гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының 23нче номерлы карары, 2018 елның 14 сентябрендәге "Җирле референдум үткәрү инициативасы турында"гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 91нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2018 елның 18 ноябренә "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан кала, 2019 елда 500 сум үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

**- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Сөйки авылында юлларны ремонтлау - Большевистская ур., Калинин ур., Карл Маркс ур., Волжская ур.;

- Сөйки авылында кышкы – җәйге чорда юлларны карап тоту;

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Красноармейская ур., авыл үзәге;

- ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз ур., 16а йорт, китапханә бинасы;

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге**
**Советы рәисе: В.П. Никитин**